КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 февраль г.Казань № 121

Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты турында нигезләмәне эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында» 2012 ел, 25 май, 422 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында» 2012 ел, 25 май, 422 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 04 май, 308 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар моңы» халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында» 2012 ел, 25 май, 422 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 29 октябрь, 811 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 17 февраль, 121 нче
карары белән расланды

Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» халыкара яшь башкаручылар телевизион конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Шәйхразыев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара берлегенең Милли Советы Рәисе, оештыру комитеты рәисе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Фәтхетдинов Салават Заки улы | Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясенең атказанган артисты, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Абзалов Азат Искәндәр улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәдәният идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Әсәдуллина Алсу Мөниб кызы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары |
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү һәм мәдәният идарәсе башлыгы |
| Нуруллин Кадыйм Назыйр улы | «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Садыйков Шамил Мөхәмәт улы | «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәитгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Хашыймова Нурия Миңнәхмәт кызы | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры (килешү буенча). |